**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«29» июль 2021 ел № 14/3

«Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 26 сентябрендәге «Җир салымы турында» 23/5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 5, 394, 397 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 26 сентябрендәге «Җир салымы турында» 23/5 номерлы карарына (2017 елның 26 декабрендәге 29/2, 2018 елның 13 сентябрендәге 23/7, 2018 елның 24 октябрендәге 24/1, 2019 елның 31 октябрендәге 8/2, 2020 елның 28 февралендәге 2/1, 2021 елның 1 апрелендәге 9/1 номерлы карарлары үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның беренче абзацында «2018 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым түләүчеләр – оешмалар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче, икенче һәм өченче кварталлары танила, дип билгеләргә.

Салым түләүчеләр – оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 1 пунктчасы рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә карата 2019 елның 1 гыйнвареннан гамәлдә була.

Әлеге карарның 1 пункты 2 пунктчасы рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк булмаган һәм 2022 елның 1 гыйнвареннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Р.М. Дусадбеков